**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 30 июлендәге 2721 номерлы карары**

# Татарстан, Шәриф Камал, Салих Сэйдәшев, Красный Пожарник, Фәткуллин, Сара Садыйкова, Габдулла Тукай, Техника, Камил Якуб урамнары чикләрендә территорияне планлаштыру проектын раслау турында

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 30 декабрендәге 4711 номерлы «Татарстан, Шәриф Камал, Салих Сэйдәшев, Красный Пожарник, Фәткуллин, Сара Садыйкова, Габдулла Тукай, Техника, Камил Якуб урамнары чикләрендә территорияне планлаштыру проектын әзерләү турында»гы карарына таянып **карар бирәм**:

1. Татарстан, Шәриф Камал, Салих Сэйдәшев, Красный Пожарник, Фәткуллин, Сара Садыйкова, Габдулла Тукай, Техника, Камил Якуб урамнары чикләрендә территорияне планлаштыру проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалану өчен

материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 30 июлендәге
2721 номерлы карары белән
расланды

**Татарстан, Шәриф Камал, Салих Сәйдәшев, Красный Пожарник, Фәткуллин, Сара Садыйкова, Габдулла Тукай, Техника, Камил Якуб урамнары чикләрендә территорияне планлаштыру проекты**

Татарстан, Шәриф Камал, Салих Сәйдәшев, Красный Пожарник, Фәткуллин, Сара Садыйкова, Габдулла Тукай, Техника, Камил Якуб урамнары чикләрендә территорияне планлаштыру проектының төп өлеше түбәндәге проект материалларыннан тора:

I. Кызыл линияләр, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре, капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымы.

II. Кызыл линияләр күрсәтелгән, кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге теркәлгән планлаштыру проекты сызымы.

III. Территорияне план буенча үстерү характеристикалары турында нигезләмә.

IV. Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә.

Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәттә файдалану документы булып тора һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

I. Чертеж проекта планировки с указанием красных линий, границ существующих и планируемых элементов планировочной структуры, границ зон размещения объектов капитального строительства.




### Объекты обслуживания нового строительства

| Обозна-чение | Наименование | Ед. изм. | Мощ-ность | Количество | Земель-ный участок, га |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| А-1 | Многофункциональный центр | Мест | 500 | 1 | 1,028 |
| **Муниципальные детские дошкольные учреждения** | | | | | |
| Д-1 | Детское дошкольное учреждение | Мест | 80 | 1 | 0,343 |
| **Объекты лечебно - оздоровительного назначения** | | | | | |
| П-1 | Поликлиника с женской консультацией | Посещений в смену | 200 | 1 | 0,577 |
| **Социальное обслуживание** | | | | | |
| СО | Дом социального обслуживания (размещение зданий, предназначенных для размещения пунктов ночлега для бездомных граждан) | Мест | 300 | 1 | 0,335 |
| **Объекты коммунального и торгово-бытового назначения** | | | | | |
| МК-1 | Магазин смешанной торговли с пристроенными объектами бытового обслуживания, в том числе: | Кв.м. общей площади | 3255 | 1 | 0,217 |
| | Магазины продовольственных и непродовольственных товаров | Кв.м. общей площади | 2940 | | |
| | | Кв.м. торговой площади | 1470 | | |
| | Предприятия бытового обслуживания | Раб. мест | 13 | | |
| | Аптечный киоск | Кв.м. общей площади | 14 | | |
| | Раздаточный пункт молочной кухни | Кв.м. общей площади | 15 | | |

### Условные обозначения:

| Обозначение | Описание |
|---|---|
| | граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки территории |
| | граница элементов планировочной структуры |
| | действующая красная линия улично-дорожной сети |
| красная линия | устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети |
| кл топ | устанавливаемая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети) |
| красная линия | отменяемая красная линия улично-дорожной сети |
| | планируемый тоннель |
| 1 | порядковый номер зоны размещения |
| 5 | вид зоны размещения объектов капитального строительства |
| 1.20 | площадь зоны размещения, га |
| 4.4 | коды видов разрешенного использования |
| н.у. | максимальная площадь жилищного фонда, (тыс.кв.м) |
| 3 | максимальная этажность, этаж |
| 2 | зона размещения среднеэтажной жилой застройки (от 5 до 8 этажей, включая мансардный) |
| 3 | зона размещения малоэтажной жилой застройки (до 4 этажей, включая мансардный) |
| 4 | зона размещения индивидуальной жилой застройки |
| 5 | зона размещения объектов общественно-делового назначения |
| 5 | зона планируемого размещения объектов общественно-делового назначения |
| 6 | зона планируемого размещения образовательных организаций |
| - | зона размещения объектов культового назначения |
| - | зона планируемого размещения объектов культового назначения |
| 7 | зона размещения объектов здравоохранения |
| 7 | зона планируемого размещения объектов здравоохранения |
| - | зона размещения объектов торговли и общественного питания |
| 10 | зона размещения объектов производственного и коммунально-складского назначения |
| 10 | зона планируемого размещения объектов производственного и коммунально-складского назначения |
| 11 | зона размещения объектов инженерной инфраструктуры |
| 11 | зона планируемого размещения объектов инженерной инфраструктуры |
| 13 | зона размещения объектов железнодорожного транспорта |
| 18 | зона размещения режимных объектов |
| 19 | зона поверхностных водных объектов |
| 20 | зона планируемых зеленых насаждений общего пользования |
| - | зона размещения озеленения специального назначения |
| 21 | зона планируемого размещения объектов улично-дорожной сети |
| | шумозащитный экран |
| | зона существующей жилой застройки в санитарно-защитной зоне |
| | планируемые БКТП (размещение условно) |

Сокращения надписей:

1. КЛ ТОП - Устанавливаемая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети)

М 1:2000

# II. Чертеж проекта планировки территории с указанием красных линий




УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ:

- граница проекта планировки территории
- действующая красная линия улично-дорожной сети
- устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети
- отменяемая красная линия улично-дорожной сети
- устанавливаемая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети)
- граница существующего технического коридора инженнерных коммуникаций и сооружений
- граница существующего технического коридора инженнерных коммуникаций и сооружений
- 9 номера характерных точек красных линий

Примечание:
Перечень координат характерных точек красных линий приведен в Приложении к II.Чертежу проекта планировки с указанием красных линий.

Сокращения надписей, принятые на чертеже:
1. красная линия - устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети
2. КЛ ТОП - устанавливаемая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети)
3. тех.кор.инж.сетей - планируемый технический коридор инженерных коммуникаций и сооружений

М 1:2000

## III. Территорияне план буенча үстерү характеристикалары турында нигезләмә

### 3.1. Территорияне планлаштыру проектының чикләре

Территорияне планлаштыру проектының чикләре булып түбәндәгеләр тора:

- төньяк-көнбатыш яктан – Татарстан, Салих Сәйдәшев урамнары;
- төньяк-көнчыгыш яктан – Красный Пожарник, Сара Садыйкова, Габдулла Тукай, Техника урамнары;
- көньяк һәм көнбатыш яктан – тимер юл.

Территориянең мәйданы 97,2 га тәшкил итә.

### 3.2. Территория характеристикалары

Карап тикшерелә торган территорияне үстерү буенча Казан шәһәр округының гамәлдәге Генераль планында салынган стратегик юнәлешләрне исәпкә алып, планлаштыру проектында түбәндәге шәһәр төзелеше чаралары каралган:

1. Район әһәмиятендәге магистраль урам салу максатыннан, тимер юл аша тоннель төзеп, Бертуган Петряевлар урамын реконструкцияләү.
2. Ватутин, Ирек, Производственная, Тимер Юл, Яңа Вахитов, Яшьләр урамнарын реконструкцияләү.
3. Балалар бакчасы һәм шәхси торак төзелеше кишәрлекләрен урнаштырып, Салих Сәйдәшев, Яшьләр һәм Фәткуллин урамнары белән чикләнгән кварталны реконструкцияләү.
4. Социаль хезмәт күрсәтү йортын һәм предприятиеләрнең санитар-сак зоналарына эләгә торган зоналарда коммуналь-склад объектларын урнаштырып, Ватутин урамындагы кварталларны реконструкцияләү.
5. Территориядә гамәлдәге планлаштырылган чикләүләрне (тимер юлдан санитар араны, җитештерү һәм коммуналь-склад предприятиеләренең санитар-сак зоналарыннан санитар ераклыкны) исәпкә алып, сәүдә-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны һәм шәхси торак төзелеше участокларын урнаштырып, Ирек урамындагы кварталларны реконструкцияләү.
6. Шәһәр үзәгенә терәлеп торучы территорияләрне исәпкә алып, халыкка хезмәт күрсәтү системасын үстерү (мәктәпкәчә балалар учреждениесен, поликлиникаларны һ.б. урнаштыру).

Планлаштыру проекты чикләрендә халык саны хисап чорына 897 кеше тәшкил итә.

1 номерлы таблица

**Яңа төзелештәге шәхси торак йортларын урнаштыру мәйданчыклары**

| Кишәр лекләр номеры | Яңа торак төзелеше урнаштырылачак кишәрлек адресы | Җир кишәрлекләре саны | Исәпләнгән халык саны (кеше) (Казан шәһәренең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары буенча бер кишәрлеккә 3.2 кеше) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Ж-1.1 | Салих Сәйдәшев, Яшьләр, Фәткуллин урамнары белән чикләнгән кварталда шәхси торак йортлар | 6 | 19 |
| Ж-1.2 | Ирек урамында шәхси торак йортлар | 4 | 13 |
| **БАРЛЫГЫ** | | **10** | **32** |

2 номерлы таблица

**Яңа төзелешкә хезмәт күрсәтү объектлары**

| **Билгеләнеше** | **Исеме** | **Үлчәү берәмлеге** | **Егәрлеге** | **Саны** | **Җир кишәрлеге, га** |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| А-1 | Күпфункцияле комплекс | Урыннар | 500 | 1 | 1,02 |
| **Муниципаль мәктәпкәчә балалар учреждениеләре** | | | | | |
| Д-1 | Мәктәпкәчә балалар учреждениесе | Урыннар | 80 | 1 | 0,34 |
| **Дәвалау-сәламәтләндерү билгеләнешендәге объектлар** | | | | | |
| П-1 | Хатын-кызлар консультациясе булган поликлиника | Бер сменага килүчеләр саны | 200 | 1 | 0,58 |
| **Социаль хезмәт күрсәтү** | | | | | |
| СО | Социаль хезмәт күрсәтү йорты (йорт-җирсез калган | Урыннар | 300 | 1 | 0,35 |

| Билгеләнеше | Исеме | Үлчәү берәмлеге | Егәрлеге | Саны | Җир кишәрлеге, га |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | гражданнар өчен төнлә кереп йоклау пунктлары урнаштыру өчен биналар урнаштыру) | | | | |
| **Коммуналь һәм сәүдә-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар** | | | | | |
| МК-1 | Кушып төзелгән көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары белән катнаш сәүдә кибете, шул исәптән | Гомуми мәйдан кв.м | 3255 | 1 | 0,22 |
| | азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товар кибетләре | Гомуми мәйдан кв.м | 2940 | | |
| | | Кв.м сәүдә мәйданы | 1470 | | |
| | көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре | Эш урыны | 13 | | |
| | даруханә киоскы | Гомуми мәйдан кв.м | 14 | | |
| | сөт кухнясының тарату пункты | Гомуми мәйдан кв.м | 15 | | |

## 3.3. Транспорт хезмәте күрсәтү системасын үстерү характеристикалары

**Районның урам-юл челтәрен үстерү:**

1. Бертуган Петряевлар урамында 1000 м озынлыкта район әһәмиятендәге магистраль урам төзү.

2. Район әһәмиятендәге магистраль урамны дәвам итеп, тимер юл аша 159 м озынлыкта тоннель төзү.

3. Җирле әһәмияттәге яңа урамнар төзү һәм реконструкцияләү: Производственная урамы, Яңа Вахитов урамы, Ватутин, Тимер Юл, Ирек, Яшьләр, Болгар урамнары участоклары һ.б. гомуми озынлык – 2821 м.

## 3.4. Инженерлык-техник яктан тәэмин итү системасын үстерү характеристикасы

### 3.4.1. Су белән тәэмин итү.

Су сибүне исәпкә алып, суның гомуми тәүлеклек чыгымы 101,39 куб.м тәшкил итәчәк.

Су белән тәэмин итү системасы хуҗалык-янгын сүндерүне берләштереп кабул ителде.

«Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенең техник шартлары буенча территорияне су белән тәэмин итү Сара Садыйкова урамындагы Ø600 мм лы боҗралы суүткәргеч челтәрләреннән каралган, ул исә үз чиратында Альфред Халиков урамын кисеп үтүче Ø800 мм лы суүткәргечкә һәм Кремль яр буе урамы тирәсендә урнашкан Ø1200 мм лы суүткәргеч белән боҗраланган үзгәртеп салына торган Ø900 мм лы челтәргә тоташа.

Планлаштыру проекты буенча түбәндәге суүткәргеч челтәрләрен салу карала:

- Габдулла Тукай урамыннан Производственная урамына кадәр Бертуган Петряевлар урамында Ø300 мм лы суүткәргечне – Ø400 мм лыга;
- Фәткуллин урамыннан Ватутин урамына кадәр Производственная урамында Ø500 мм лы суүткәргечне – Ø600 мм лыга.

Планлаштыру проекты буенча Ø400 мм лы, Ø600 мм лы суүткәргеч челтәрләрен төзү карала:

- Производственная урамыннан Яңа Вахитов урамына кадәр Ватутин урамында – Ø400 мм лы;
- Яңа Вахитов урамыннан Ирек урамына кадәр Тимер Юл урамында – Ø400 мм лы;
- Производственная урамыннан Шәриф Камал урамына кадәр Бертуган Петряевлар урамында – Ø400 мм лы;
- Тимер Юл урамыннан Салих Сәйдәшев урамына кадәр Шәриф Камал урамында – Ø400 мм лы;
- Шәриф Камал урамыннан Салих Сәйдәшев урамында – Ø400 мм лы;
- Габдулла Тукай урамыннан Производственная урамына кадәр Ватутин урамында – Ø600 мм лы;
- Фәткуллин урамыннан Ватутин урамына кадәр Фәткуллин урамында – Ø600 мм лы.

Планлаштыру проекты буенча эчке мәйданда Ø110-160 мм лы суүткәргеч челтәрләрен төзү карала.

Салих Сәйдәшев урамы, Фәткуллин урамы буенча шәхси торак йортларны (Ж-1.1) якынча йөкләнеш 3,51 куб.м/тәүлек булган күләмдә су белән тәэмин итү өчен, Салих Сәйдәшев урамында Ø200 мм лы суүткәргечкә тоташтырып, Ø110 мм лы су белән тәэмин итү челтәре төзү карала.

Ирек урамы буенча шәхси торак йортларны (Ж-1.2) якынча йөкләнеш 2,40 куб.м/тәүлек булган күләмдә су белән тәэмин итү өчен, Шәриф Камал

урамында Ø150 мм лы суүткәргечкә тоташтырып, Ø110 мм лы су белән тәэмин итү челтәре төзү карала.

Күпфункцияле комплексны (гомуми белем мәктәбе аналогиясе буенча) (А-1) якынча йөкләнеш 55,52 куб.м/тәүлек булган күләмдә су белән тәэмин итү өчен, Производственная урамында Ø300 мм лы суүткәргечкә тоташтырып, Ø110 мм лы су белән тәэмин итү челтәре төзү карала.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениесен (Д-1) якынча йөкләнеш 1,76 куб.м/тәүлек булган күләмдә су белән тәэмин итү өчен, Фәткуллин урамында Ø250 мм лы суүткәргечкә тоташтырып, Ø63 мм лы су белән тәэмин итү челтәре төзү карала.

Поликлиниканы (П-1) якынча йөкләнеш 2,60 куб.м/тәүлек булган күләмдә су белән тәэмин итү өчен, Шәриф Камал урамында Ø160 мм лы суүткәргечкә тоташтырып, Ø63 мм лы су белән тәэмин итү челтәре төзү карала.

Социаль хезмәт күрсәтү йортын (СО) якынча йөкләнеш 25,50 куб.м/тәүлек булган күләмдә су белән тәэмин итү өчен, Ватутин урамында Ø110 мм лы суүткәргечкә тоташтырып, Ø110 мм лы су белән тәэмин итү челтәре төзү карала.

Кушып төзелгән көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары булган катнаш сәүдә кибетләрен (МК-1) якынча йөкләнеш 7,86 куб.м/тәүлек булган күләмдә су белән тәэмин итү өчен, Шәриф Камал урамында Ø150 мм лы суүткәргечкә тоташтырып, Ø110-160 мм лы су белән тәэмин итү челтәре төзү карала.

Территорияне планлаштыру проектының яңа төзелеш объектларын киләчәктә проектлаштырылган һәм яңадан салына торган магистраль суүткәргеч челтәрләренә тоташтыру тәкъдим ителә. Төзелеш процессында гамәлдәге төзелешне шулай ук яңа проектлаштырылган челтәрләргә күчерү зарур.

Проектлана һәм күчерелә торган челтәрләрнең гомуми озынлыгы – 5,5 км, шуларның күчерелә торганнары – 1,34 км.

### 3.4.2. Су чыгару.

Карала торган территориядә агынты суларның тәүлеклек чыгымы 99,15 куб.м тәшкил итәчәк.

«Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенең техник шартлары нигезендә проект буенча Альфред Халиков урамында урнашкан «Главная» канализация насос станциясенә кадәр үзагышлы хуҗалык-көнкүреш канализациясе төзү карала.

Проект белән Салих Сәйдәшев урамы буенча үзагышлы хуҗалык-көнкүреш канализациясенең яңадан салына торган Ø315 мм лы челтәренә кадәр су чыгару челтәрләре төзү карала, ул «Үзәк» территориясен планлаштыру проекты буенча Татарстан урамы буенча гамәлдәге Ø900 мм лы коллекторга, аннары Альфред Халиков урамы буенча «ГНС» канализация-насос станциясенә тоташа.

Проект белән көнкүреш канализациясен төзү карала:

- Фәткуллин урамыннан Яңа Вахитов урамына кадәр Шәриф Камал урамында – Ø160 мм лы;

- Шәриф Камал урамыннан Бертуган Петряевлар урамына кадәр Яңа Вахитов урамында – Ø160 мм лы;

- Гассар урамыннан Габдулла Тукай урамына кадәр Ватутин урамында – Ø225 мм лы;

- Ватутин урамыннан алып Габдулла Тукай урамы буенча – Ø225 мм лы;

- Производственная урамыннан Габдулла Тукай урамына кадәр Фәткуллин урамында – Ø225 мм лы;

- Шариф Камал урамына кадәр Салих Сәйдәшев урамы буенча – Ø315 мм лы;

- Салих Сәйдәшев урамыннан Фаткуллин урамына кадәр Шариф Камал урамында – Ø315 мм лы.

Салих Сәйдәшев урамы, Фәткуллин урамы буенча шәхси торак йортлардан (Ж-1.1) якынча йөкләнеш 3,51 куб.м/тәүлек булган күләмдә хуҗалык-көнкүреш юынтык суларын чыгару өчен, Кызыл Пожарник урамы һәм Плетеневский тыкрыгы киселешендә, Кәрим Тинчурин урамы буенча 31 йорт тирәсендә, квартал эчендәге Ø300 мм лы канализация коллекторына тоташтырып, Ø160 мм лы су чыгару челтәре төзү карала.

Ирек урамы буенча шәхси торак йортларның (Ж-1.2) якынча йөкләнеш 2,40 куб.м/тәүлек булган күләмдә хуҗалык-көнкүреш юынтык суларын чыгару өчен, Шәриф Камал урамы буенча 54,98/52,31 тамгасы булган коедан 54,74/52,08 тамгасы булган коега кадәрге участокта Ø300 мм лы канализация коллекторына тоташтырып, Ø160-225 мм лы су чыгару челтәре төзү карала.

Күпфункцияле комплексның (гомуми белем мәктәбе аналогиясе буенча) (А-1) якынча йөкләнеш 55,52 куб.м/тәүлек булган күләмдә хуҗалык-көнкүреш юынтык суларын чыгару өчен, Сара Садыйкова урамы буенча Ø300 мм лы канализация коллекторына тоташтырып, Ø225 мм лы су чыгару челтәре төзү карала.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениесенең (Д-1) якынча йөкләнеш 1,76 куб.м/тәүлек булган күләмдә хуҗалык-көнкүреш юынтык суларын чыгару өчен, Сара Садыйкова урамы буенча Ø300 мм лы канализация коллекторына тоташтырып, Ø160-225 мм лы су чыгару челтәре төзү карала.

Поликлиниканың (П-1) якынча йөкләнеш 2,60 куб.м/тәүлек булган күләмдә хуҗалык-көнкүреш юынтык суларын чыгару өчен, Шәриф Камал урамы буенча 54,98/52,31 тамгасы булган коедан 54,74/52,08 тамгасы булган коега кадәрге участокта Ø300 мм лы канализация коллекторына тоташтырып, Ø160-225 мм лы су чыгару челтәре төзү карала.

Социаль хезмәт күрсәтү йортының (СО) якынча йөкләнеш 25,50 куб.м/тәүлек булган күләмдә хуҗалык-көнкүреш юынтык суларын чыгару өчен, Тимер Юл урамы буенча Ø1000 мм лы канализация коллекторына тоташтырып, Ø160-225 мм лы су чыгару челтәре төзү карала.

Кушып төзелгән көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары булган катнаш сәүдә кибетенең (МК-1) якынча йөкләнеш 7,86 куб.м/тәүлек булган күләмдә хуҗалык-көнкүреш юынтык суларын чыгару өчен, Шәриф Камал урамы буенча 54,98/52,31 тамгасы булган коедан 54,74/52,08 тамгасы булган коега кадәрге участокта Ø300 мм лы канализация коллекторына тоташтырып, Ø160- 225 мм лы су чыгару челтәре төзү карала.

Проектлаштырыла торган канализация челтәрләренең гомуми озынлыгы – 3,5 км.

**3.4.3. Яңгыр канализациясе.**

Территориядә өслек суларының исәпләнгән чыгымы секундына 4434,49 л тәшкил итә.

Проектта яңгыр канализациясенең урам челтәрләрен төзү карала:

- Ø500-630 мм лы – Производственная урамыннан Фаткуллин урамына кадәр;

- Ø630 мм лы – Тимер Юл урамыннан Яңа Вахитов урамына кадәр Бертуган Петряевлар урамы буенча;

- Ø630 мм лы – Бертуган Петряевлар урамы буенча Яңа Вахитов урамына кадәр;

- «Үзәк» территориясен планлаштыру проекты нигезендә Шәриф Камал урамы буенча Яңа Вахитов урамыннан Татарстан урамы буенча проектлаштырылган Ø2000 мм лы коллекторга кадәр Ø800 мм лы канализация коллекторы. Яңа өйләнешүчеләр паркы территориясендә урнашкан чистарту корылмаларында агынтылар чистартылганнан соң, су Идел елгасына агызыла.

Габдулла Тукай һәм Бертуган Петряевлар урамнары киселешендә проектлаштырылган Ø630 мм лы челтәр Техника урамындагы чистарту корылмаларында чистарту уза торган яңадан салынучы Ø800-1000 мм лы яңгыр канализациясе челтәренә тоташтырылырга тиеш.

Шулай ук проект буенча Яшляр урамында Ø1000 мм лы канализацияне күчереп салу каралган.

Проектлана торган яңгыр канализация челтәрләренең гомуми озынлыгы – 3,60 км.

### 3.4.4. Җылылык белә тәэммин итү.

Яңа төзелеш объектларында җылылыкны гомуми куллану 4,742 МВт (4,077 Гкал/сәг) тәшкил итә.

1. Күпфункцияле комплексны (А-1) җылылык белән тәэмин итү челтәрләренә Фәткуллин урамындагы җылылык магистралендә гамәлдәге ТК-2 җылылык камерасына тоташтыру каралган.

2. 80 урынлык мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениесен (Д-1) җылылык белән тәэмин итү челтәрләренә ТК-1 дәге 2Ø326 мм лы гамәлдәге җылылык үткәргечкә тоташтыру каралган.

3. Планлаштыру проектында поликлиника (П-1) территориясеннән җылылык челтәрләре участогын күчерү, алга таба гамәлдәге объектларны тоташтыру каралган. 2Ø219 мм лы җылылык үткәргеч Шәриф Камал урамында гамәлдәге ТК-4 тән гамәлдәге ТК-5 кә кадәр проектлаштырылган.

4. Кушып төзелгән көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары булган катнаш сәүдә кибетен (МК-1) җылылык белән тәэмин итү «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – Казан җылылык челтәрләре (алга таба – Казан җылылык челтәрләре) тарафыннан бирелгән объектларны тоташтыру схемасы нигезендә гамәлдәге ТК-2 дә каралган.

5. Ватутин урамындагы социаль хезмәт күрсәтү йортын гамәлдәге җылылык үткәргеченә ТК-1 тоташтыру Казан җылылык челтәрләре тарафыннан бирелгән схема буенча каралган.

6. Салих Сәйдәшев урамы, Фәткуллин урамы, Ирек урамы буенча шәхси торак йортларны җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итү Celtic DS ESR фирмасының 40,7 кВт егәрлекле ике контурлы шәхси газ казаннарыннан башкарыла.

7. Иҗтимагый һәм коммуналь билгеләнеш объектларына кадәр гомуми озынлыгы 1,6 км булган җылылык үткәргечләр салу каралган.

### 3.4.5. Электр белән тәэмин итү.

Кулланучыларны электр белән тәэмин итүнең ышанычлылык категориясе – II.

Яңа төзелеш объектларының исәпләнгән егәрлеге 954,14 кВт тәшкил итә.

Электр белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы һәр блоклы комплектлы трансформатор подстанциясен ике яктан тукландырып, 6 кВ челтәрләренең 2 нурлы схемасын куллану хисабына тәэмин ителә.

0,4 кВ челтәрләре өчен үзара резервланучы тоташу урыннары булган радиаль схема каралган.

Планлаштыру проекты белән түбәндәгеләр каралган:

1. Ике трансформаторга 6 кВ га кадәр дүрт кабель тоташтырыла торган блоклы комплектлы трансформатор подстанцияләре төзү: 160 кВА га кадәр блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе; 250 кВА га кадәр блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе; 400 кВА га кадәр блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе.

2. Яңа 1 нче блоклы комплектлы трансформатор подстанциясен (беренче һәм икенче шина секцияләреннән) ТП-153 нең РУ-6кВ на (беренче һәм икенче шина секцияләреннән) АПвПг-10-3(1х240/95) кв.мм маркалы кабельләр белән тоташтыру.

3. Яңа 3 нче блоклы комплектлы трансформатор подстанциясен (беренче һәм икенче шина секцияләреннән) ТП-163 нең РУ-6кВ на (беренче һәм икенче шина секцияләреннән) АПвПг-10-3(1х240/95) кв.мм маркалы кабельләр белән тоташтыру.

4. Яңа 5 нче блоклы комплектлы трансформатор подстанциясен (беренче һәм икенче шина секцияләреннән) ТП-1027 нең РУ-6кВ на (беренче һәм икенче шина секцияләреннән) АПвПг-10-3(1х240/95 кв.мм маркалы кабельләр белән тоташтыру.

5. 6 кВ лы кабель линиясен АПвПг-10-3(1х240/95) маркалы кабельләр белән салу:

- 1 нче блоклы комплектлы трансформатор подстанциясенең РУ-6кВ дан (беренче һәм икенче шина секцияләреннән) 2 нче блоклы комплектлы трансформатор подстанциясенә (беренче һәм икенче шина секцияләренә) кадәр;

- 3 нче блоклы комплектлы трансформатор подстанциясенең РУ-6кВ дан (беренче һәм икенче шина секцияләреннән) 4 нче блоклы комплектлы трансформатор подстанциясенә (беренче һәм икенче шина секцияләренә) кадәр;

6. Электр энергиясен кулланучылар тоташкан урында электр энергиясен гомуми исәпкә алу җайланмасын урнаштыру.

7. Җиргә тоташтыру Электр җайланмаларыннан файдалану кагыйдәләре (7 басма) нигезендә башкарыла.

**3.4.6. Газ белән тәэмин итү.**

Планлаштыру проекты чикләрендә проектлаштырылган торак йортларны газ белән тәэмин итү өчен 39,8 куб.м/сәг газ кирәк.

Ж1.1 торак йортларын газ белән тәэмин итү Салих Сәйдәшев урамы буенча гамәлдәге түбән басымлы Ø114 мм лы газүткәргечтән каралган.

Ирек урамындагы Ж1.2 торак йортларын газ белән тәэмин итү Ирек урамында урнашкан Ø100 мм лы гамәлдәге газүткәргечтән башкарыла.

Проектта гомуми озынлыгы 185 м озынлыгында түбән басымлы Ø63,110 мм лы газүткәргечләр салу каралган.

**3.4.7. Элемтә челтәрләре.**

Телефон элемтәсе белән тәэмин итү, мәгълүмат тапшыру хезмәтләре күрсәтү, интернетка тоташтыру өчен проектта карала:

- проектлаштырылган торак йортларда, халыкка хезмәт күрсәтү объектларында агрегация узеллары (УА) урнаштыру;
- торак йортларга сыйдырышлылыгы кимендә 8 җепселле булган һәм башка билгеләнештәге объектларга кимендә 4 җепселле булган җепселле-оптик кабельләр салу;
- шушы урында гамәлдәге «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең электр тапшыру һава линиясе буйлап җепселле-оптик элемтә линиясенең һава участогын кабель ярдәмендә үзгәртеп төзү.

Проектта асбест-цемент торбалардан, җыелма тимер-бетон коеларны һәр 70-90 метр саен урнаштырып, бер- һәм ике тишемле кабель канализациясе төзү карала. Кабель канализациясе салу таләпләре нигезендә инженерлык коммуникацияләренең уртак коридорларында салына.

## IV. Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә

Чараларны гамәлгә ашыруның этаплары һәм максималь сроклары 3 номерлы таблицада китерелгән.

3 номерлы таблица

**Чараларны гамәлгә ашыруның этаплары һәм максималь сроклары**

| Капиталь төзелеш объектлары төрләре | Объектлар | Максималь сроклар, елларда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Төзелеш алып барыла торган территориядә урнашкан гамәлдәге объектларны сүтү | Архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру* | Төзү** |
| **1 нче этап** | | | | |
| Социаль инфраструктура | 80 урынлык мәктәпкәчә белем бирү оешмасы (Д1), 300 урынлык социаль хезмәт күрсәтү йорты | 2032 | 2030 | 2035 |
| Инженерлык инфраструктурасы | БКТП-1-БКТП-5, инженерлык челтәрләре | 2032 | | |
| Транспорт инфраструктурасы | Урам-юл челтәре | 2032 | | |
| **2 нче этап** | | | | |
| Социаль инфраструктура | Күпфункцияле комплекс | 2038 | 2035 | 2040 |
| Инженерлык инфраструктурасы | Күпфункцияле комплекска хезмәт күрсәтү өчен инженерлык челтәрләре | 2038 | | |
| Транспорт инфраструктурасы | Район әһәмиятендәге магистраль урамны дәвам итеп тимер юл аша 159 м озынлыкта тоннель һәм якындагы урам-юл челтәре | 2038 | | |

* Төзелешкә рөхсәттә төгәлләштерелергә мөмкин;

** социаль инфраструктура объектларын проектлау һәм төзү вакыты дәүләт һәм муниципаль программаларны формалаштыру вакытына карап төгәлләштерелергә мөмкин.

_______________